**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 28 декабрь № 991

г. Казань

«2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасында товарлы аквакультураны (товарлы балыкчылыкны) үстерү» дәүләт программасын раслау турында

«Аквакультура (балыкчылык) турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 2 июлендәге 148-ФЗ номерлы Федераль законны, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 ел, 15 апрель 314 нче карары белән расланган «Балык хуҗалыгы комплексын үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы, Россия Федерациясе авыл хуҗалыгы министрлыгының «2015 – 2020 елларга Россия Федерациясендә товарлы аквакультураны (товарлы балыкчылыкны) үстерү» тармак программасын раслау турында» 2015 ел, 16 гыйнвар, 10 нчы боерыгын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән «2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасында товарлы аквакультураны (товарлы балыкчылыкны) үстерү» дәүләт программасын (алга таба – Программа) расларга.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгын Программаның дәүләт заказчысы итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына ел саен чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда, мөмкинлекләрне исәпкә алып һәм әлеге максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан җибәрелә торган акча кысаларында, Программа чараларын тормышка ашыруга акча каралрга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\991.docx